ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 22 июнендәге 425 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.3 пункты, 9.4 пунктындагы беренче абзацы, 9.5 пунктындагы беренче абзацының аерым нигезләмәләре һәм 9.8 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.П. Луговнина шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

Казан шәһәре 2017 елның 23 июне

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Г.П. Луговнина шикаятен алдан өйрәнгән судья Л.В. Кузьмина бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.П. Луговнина Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 22 июнендәге 425 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Нигезләмә) 9.3 пункты, 9.4 пунктындагы беренче абзацы, 9.5 пунктындагы беренче абзацының аерым нигезләмәләре һәм 9.8 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм

ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Нигезләмәнең дәгъвалана торган нормалары белән шул билгеләнгән: транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү алу максатында гариза бирүчеләр үз инициативалары белән Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге (алга таба — Үзәк) бүлегенә Нигезләмәнең 9.2, 9.11 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматлар бирелгән документларны кертергә хокуклы (9.3 пункт); Нигезләмәнең 9.1 пунктындагы кертелгән документлар һәм Нигезләмәнең 9.2, 9.11 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматлар нигезендә Үзәк бүлеге кирәкле барлык документлар белән бергә транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү турында яисә аны билгеләүдән баш тарту хакында карар кабул итә һәм кабул ителгән карар турында бу гариза бирүчеләргә гаризада күрсәтелгән ысул (почта адресы буенча хат рәвешендә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга смс-хәбәр белән, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында шәхси кабинет аша) белән хәбәр итә (9.4 пунктның беренче абзацы); транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү барлык кирәкле документлары белән гариза бирелгән айдан башлап билгеләнә һәм билгеләнгән айдан башлап алты ай дәвамында түләнә (9.5 пунктның беренче абзацы); транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү өчен уртача айлык керем барлык кирәкле документлары белән транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза тапшырган айга кадәрге соңгы алты календарь ай өчен билгеләнә (исәп чоры) (9.8 пункт).

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — пенсионер һәм аңа 2016 елның 1 октябреннән 2017 елның 31 мартына кадәр, мөрәҗәгать итү моментына аның уртача айлык кереме 20 000 сумнан артып киткәнгә күрә, 2016 елда 280 сум һәм 2017 елда 180 сум күләмендә транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләнгән. Ләкин, гражданка Г.П. Луговнина күрсәткәнчә, 2016 елның 30 декабреннән ул хезмәт эшчәнлеген туктаткан һәм транспортта

йөрүгә айлык акчалата түләүне, мөрәҗәгать итү моментына аның уртача айлык кереме 20 000 сумнан кимрәк булганга күрә, яңадан карау турында мөрәҗәгать иткән. Мөрәҗәгать итүче, транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү өчен уртача айлык керем аны билгеләү турында гариза тапшырган айга кадәрге соңгы алты календарь айдан чыгып исәпләнгәнгә күрә, аңа бирелә торган транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү күләме үзгәрмәгән дип саный. Гражданка Г.П. Луговнина фикеренчә, моның сәбәбе булып Нигезләмәнең аның тарафыннан дәгъвалана торган 9.5 пунктының беренче абзацының аерым нигезләмәләре һәм 9.8 пунктының айлык акчалата түләү билгеләнгән вакыт эчендә уртача айлык керемнең үзгәрә алуын исәпкә алмаулары тора, бу исә аның конституциячел хокукларын боза.

Моннан тыш, гражданка Г.П. Луговнина Нигезләмәнең дәгъвалана торган 9.3 пунктының һәм 9.4 пунктындагы беренче абзацының транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү турында карар кабул итәр өчен Нигезләмәнең 9.11 пунктында күрсәтелгән кирәкле мәгълүматлар тапшыруны, Нигезләмәдә андый номерлы пункт булмаса да, күздә тотуларына игътибар итә. Әлеге таләптә, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, эчтәлеге буенча билгесезлек бар, шуның белән аның конституциячел хокуклары шулай ук бозыла.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Г.П. Луговнина Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 22 июнендәге 425 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.3 пунктын, 9.4 пунктындагы беренче абзацын, 9.5 пунктындагы беренче абзацының аерым нигезләмәләрен һәм 9.8 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче өлеш), 29 (беренче өлеш), 38 (беренче өлеш), 49 һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәгъвалана торган карары нигезендә транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү бирү мәсьәләсе Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын тәшкил иткән иде инде, ул күрсәтелгән түләү үзенең хокукый табигате буенча федераль законнар нормаларына нигезләнеп билгеләнә торган социаль яклау чаралары исәбенә керми дип билгеләде. Бу түләү федераль законнарда аналогы булмаган өстәмә социаль ярдәм чарасы булып тора, аны билгеләү «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3.1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасының бурычы түгел, ә хокукы булып тора һәм, барыннан да элек, Татарстан Республикасының финанс мөмкинлекләре белән билгеләнә. Димәк, әлеге түләүне бирү шартлары һәм күләме, бу түләүләрне тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы бюджетының реаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә, бу исә «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы икенче өлеше эчтәлегеннән килеп чыга (2012 елның 4 июлендәге 49-П номерлы карар).

Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр билгеләп үткәнчә, Россия Федерациясе Конституциясе, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклауны Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагына кертеп (72 статья, 1 өлешнең «ж» пункты), гражданнарның теге яки бу категорияләренә бирелә торган мондый яклауның конкрет ысулларын һәм күләмнәрен билгеләми. Әлеге мәсьәләләрне хәл итү закон чыгаручының аерым хокукы булып тора, ул Россия Федерациясе Конституциясендә беркетелгән хокукларны гамәлгә ашыру гарантияләрен билгеләгәндә социаль яклау чараларын, аларны дифференциацияләү критерийларын, күрсәтелү шартларын һәм тәртибен регламентацияләүне сайлап алганда җитәрлек дәрәҗәдә иркле эш итә; ул шулай ук аларның күрсәтелү формаларын (ысулларын) сайлап алырга

һәм үзгәртергә хокуклы (2009 елның 10 ноябрендәге 17-П номерлы Карар; 2010 елның 9 ноябрендәге 1439-О-О номерлы Билгеләмә).

Нигезләмәнең мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган 9.5 һәм 9.8 пунктлары үзара бәйләнештә торалар һәм үзләренең эчтәлеге һәм хокукый мәгънәсе буенча транспортта йөрүгә айлык акчалата түләүне билгеләү һәм исәпләүнең оештыру-процедура механизмы булып торалар һәм аның күләмен һәм түләү периодын исәпләүнең нинди дә булса өстәмә нигезсез шартларын билгеләмиләр.

Шулай, әлеге период өчен уртача айлык керем турындагы мәгълүматны исәпкә алып, акчалата түләүләр күләме үзгәртелергә тиеш булмаган алты айлык вакыт социаль ярдәм чараларын билгеләү өчен федераль һәм республика законнарында кулланыла («Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр бирү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 14 декабрендәге 761 номерлы карарының 32 пункты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәнең 2.3.1 пункты).

Мондый алым гражданнарга артырга да, кимергә дә мөмкин булган уртача айлык керемнәренең үзгәрүенә бәйсез рәвештә билгеләнгән период эчендә түләүне бер үк күләмдә алу мөмкинлеген тигез дәрәҗәдә гарантияләргә ирек бирә.

Шулай итеп, Нигезләмәнең карала торган нормалары үзләреннән-үзе гражданнарның конституциячел хокукларын боза торган буларак карала алмыйлар һәм, димәк, аларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Нигезләмәнең 9.3 пунктында һәм 9.4 пунктындагы беренче абзацында сылтама ясалган 9.11 пунктның Нигезләмә текстында булмавы мәсьәләсенә килгәндә, Татарстан Республикасы Конституция суды шуңа игътибар итә: «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 20 декабрендәге 959 номерлы карары белән билгеләнгәнчә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәдә «9.9—9.11» пунктларны тиешенчә «9.8—9.10» пунктлар дип санарга (1 пунктның алтынчы абзацы). Моны исәпкә алып, Нигезләмәнең гражданка Г.П. Луговнина тарафыннан дәгъвалана торган 9.3 пунктында һәм 9.4 пунктының беренче абзацында 9.11 пунктына сылтамаларны күрсәтелгән Нигезләмәнең 9.10 пунктына сылтамалар дип санарга кирәк. Шуңа бәйле рәвештә дәгъвалана торган нигезләмәләрдә аларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Ләкин бу Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетын аның тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актларга үзгәрешләр керткәндә юридик техника кагыйдәләрен үтәүдән азат итми. Шулай итеп, мөрәҗәгать итүченең шикаяте Нигезләмәнең конституциячеллеген аны бастырып чыгару формасы буенча тикшерү өлешендә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә шулай ук карала алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72 һәм 73 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 22 июнендәге 425 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.3 пункты, 9.4 пунктындагы беренче абзацы, 9.5 пунктындагы беренче абзацының аерым нигезләмәләре һәм 9.8 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Г.П. Луговнина шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки шикаять «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Г.П. Луговнинага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 24-О** **Татарстан Республикасы Конституция суды**